# Светофор сүзе

**Усманова Г. М.**
Әлмәт шәһәренең 9 нчы «Садко» балалар бакчасы.

Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары өчен

**Максат**: Туган шәһәребезнең мәдәният хезмәткәрләре белән таныштыруны дәвам итеп, аларның иҗади һәм шигъри әсәрләренә карата кызыксыну уяту. Юл хәрәкәте кагыйдәләрен үтәүгә аңлы караш булдыруга ярдәм итү. Балаларда коммуникатив сыйфатлар, туган телдә аралашу омтылышы тәрбияләү.

**Җиһазлау**:Юл билгеләре (рәсемнәр,- макетлар); инсценировка өчен костюмнар, атрибутлар; слайдлар.юл билгеләре төшкән төрле төстәге шарлар, аудиоязмалар.

**Алдан әзерләнгән эшләр:**Язучы Р.Фәрхетдинованың китапларын карау шигырьләрен өйрәнү , юл билгеләрен искә төшерү.

Эшчәнлекнең барышы:

- Балалар,без сезнең белән тизлек гасырында яшибез.Безнең әйләнә-тирәбездә барысы да каядыр ашыга, йөгерә, ә урам һәм юл законнары бик кырыс.Ул беркемне дә гафу итми.Ни өчен юл законнарын кырыс дибез соң? Балалар,сез ничек уйлыйсыз?
**Бала:** Урамда җәяүлегә ничек тели шулай йөрергә ярамый,юл йөрү кагыйдәләрен төгәл үтәргә кирәк.
**Ал.бар:** Ә бу закон үзенчә бик мәрхәмәтле дә. Сез төшенгәнсездер инде, ни өчен мәрхәмәтле?
**Бала:** Ул безне аварияләрдән, төрле бәла-казалардан, кайгылардан саклый.
**Ал.бар:** Без сезнең белән барыбызда юл хәрәкәтендә катнашучылар.Юл хәрәкәтендә катнашучылар кемнәр соң алар ?
**Бала:** Машина йөртүчеләр, җәяүлеләр, пассажирлар.
**Ал.бар:** Шуңа күрә үзебезгә дә,башкаларга да куркыныч хәлләр тудырмас өчен без –җәяүлеләр нәрсәне яхшы белергә тиеш?
**Бала:** Юл йөрү кагыйдәләрен.
**Ал.бар:** Бик дөрес, балалар.Сезнең яшьтә иң кирәклеләрен истә тотарга кирәк, менә шулар турында бүген сөйләшербез.
Бүген, балалар, мин сезгә серле ил турында сөйләрмен.Анда бик күп юллар, урам аша чыгу юллары, җәяүле юллары, урамнар.Анда искиткеч кешеләр яши. Аларның һәрберсе үз эшен белә. Бу илдә беркайчанда юл һәлакәтләре булмый. Ни өчен булмый, сез ничек уйлыйсыз?
**Бала:** Чөнки бу илдә бөтен кеше дә юл кагыйдәләрен белә һәм аларны бозмый.
**Ал.бар:** Ә сезнең бу илгә барасыгыз киләме?
**Балалар:** Әйе, килә!
**Ал.бар:** Алай булса, барыгыз да тиз генә светофор сигналларын кабатлагыз, аннан тыючы, кисәтүче, боеручы, хезмәт күрсәтүче билгеләрне искә төшерегез, тагын урам аша чыгу кагыйдәләрен онытмагыз, транспорт төрләрен искә төшерегез.
**Балалар:** У-у-у, без аларны беләбез.
**Ал.бар:** Ярый,светофорны гына көтик тә, кузгалырбыз.Тик нигәдер ул күренми.
( "Зеленый свет"көенә Убыр керә)
**Убыр:** Ә-ә-ә! Сез каядыр җыендыгыз?! Кемне көтәсез инде?
**Балалар:** Светофорны көтәбез.
**Убыр:** Нәрсәгә ул сезгә, нигә кирәге бар аның? Ул минем башны әйләндереп бетерде, әйрәтә дә әйрәтә.Унга кара аннан сулга кара башың өзелеп төшәр аның кагыйдәләре белән йөри башласаң. Ә сезгә нәрсәгә соң светофор?
**Ал.бар:** Ничек инде нәрсәгә!Балалар, светофорның кирәклеген убырга аңлатып китик әле.
**Бала:** Юлларда тәртип булсын өчен, Ул юл хәрәкәтен көйли.Светофор ике төрле була, машина йөртүчеләр өчен өч күзле, ә җәяүлеләр өчен - ике. Әле ул тавыш сигналы белән дә була.
**Бала:** Убыр әйт әле, янгын сүндерү машинасы нинди төстә?
**Убыр:** Белмим, урманда бит янгын сүндерү машинасы йөрми.
**Бала:** Ул кызыл төстә, кызыл төс куркыныч килгәнне хәбәр итә, шуңа күрә кызыл төстәге янгын сүндерү машинасын күреп барлык машиналар да як-якка туктап аңа юл бирәләр.Светофорның кызыл төсенә дә туктарга кирәк.
**Убыр:** Ә сары төс нигә?
**Бала:** Бу төс кисәтә:"Игътибарлы бул!"- ди. Юл эшләрендә эшли торган машиналар: бульдозерлар, краннар, асфальт катоклары сары төстә. Юлда эшли торган эшчеләрнең дә өс киемнәре сары төстә.Шоферлар сары төстәге машиналарны ерактан күреп тизлекләрен киметәләр. Сары светофор төсе дә ашыкмагыз дигәнне аңлата.
**Бала:** Яшел төскә тыныч кына юл аша чыгып була.
**Убыр:** Бу яшел үләннәр, яфраклар төсе, минем урманым төсе, тыныч, рәхәт төс.
**Бала:** Яшел төс янса да, игътибарлы булырга кирәк.Элек сулга, аннан уңга каpарга кирәк.
/Убыр башын чайкый, аның кулында юл билгеләре/
**Ал.бар:** Убыр, ә син нигә юл билгеләрен үзең белән йөртәсең?
**Убыр:** Юлда барганда комачаулап торалар, менә шуларга килеп бәрелеп башымны тишә яздым. Ә менә бу рәсемне үзем белән алдым, бу минем хыялым./ "велосипед юлы" билгесен күрсәтә/
Әгәр велосипед күрсәм,
Утырып барасы килә.
Кин урамнардан җилдереп,
Эх, бер чабасы килә!
Карагыз әле, ә сезнең сәпиттә йөрисегез киләме? Я, кайсыгыз сәпиттә йөрергә хыяллана?
**1 бала:** Мин!
**2бала:** Мин дә хыялланам!
/ Ике малай йөгереп чыгалар/
**1 бала:** Хыялланып барган чакта,
Мин абындым бер ташка.
Килеп төштем борын белән,
Авыртты хәтта баш та.
Абый шунда мине күреп,
Әй тотынды көләргә,
Әйтте:
**2 бала:** "Нинди сәпит ди ул,
Өйрән җәяү йөрергә."
**Ал.бар:** Менә, балалар, бу бәләкәй малай хәлендә калмас өчен юлда йөргәндә аяк астына карап йөрергә кирәк.
**Убыр:** Хыялланып утырып сөякләр авырта башлады.Ягез, туп уйнап алыйк әле,әйдәгез кайсыгыз җитез?
/Ике малай спорт киемнәреннән һәм машина макеты тоткан өченче малай чыга/.
**1 бала:** Ишек алдына чыгып,
Футбол уйныйбыз кызып.
**2 бала:** Футбол уйнавы кызык.
**1 бала:** Каршыда юлыбызда
Туктап тора машина.
Ялгыш тиде тубыбыз.
Куркып куйдык үзебез.
**2 бала:** Машина ошатмады.
**3 бала:** "Ой-ей-ей,"-дип кычкырды,
"Фьють,фьють,фьють,"-дип сызгырды.
"Кит! Кит!"-дип безне куды.
**1 бала:** Һәм кисәтте ул безгә:
**3 бала:** Юлдан читтә уйнагыз!
Мәйданчыктан чыкмагыз!
Үзегезне саклагыз!
**Ал.бар:** Менә, Убыр, юл кагыйдәләренең һәм юл билгеләренең кирәклегенә инандыңмы инде . Кагыйдәләр синең исеңдә ныграк калсын өчен без сиңа алар турында шигырьләр сөйләп китәбез.
/Һәр бала юл билгесен күрсәтеп сөйли/
**Бала:** Бу билгене күрсәләр,
Шоферлар уйланалар.
Димәк, тиздән бакча, мәктәп,
Игътибарга алалар.
**Бала:** Юлда аклы сызык күрсәң-
Булыр чыгу урыны.
Мин булмаган җирдән чыксаң-
Машина булэр юлыңны.
**Бала:** Бу билгене күргәч тә,
Сөенә авырулар,
Димәк, якында гына
Ярдәм күрсәтүчеләр.
**Бала:** Бу билгегә карасаң,

Сөенеп тә куясың,
Ярый әле машина
Алмаганнар әтиләр
Велосипедта гына
Йөрергә кирәк диләр.

**Ал.бар:** Балалар, юл билгеләре Убырның исендә ныграк калсын өчен, әйдәгез, бергәләп уйнап алыйк.Уен "Төркемнәргә бүл"-дип атала.Менә сезнең алдыгызда юл билгеләре, шуларны дүрт төркемгә бүлергә кирәк.Нинди төркемнәр икәнен искә төшереп үтик әле.

**Балалар**:Тыючы, кисәтүче, мәгълүмат бирү-күрсәтү, махсус билгеләр.

**Ал.бар:** Уенны башладык.

/Күңелле бию көенә балалар юл билгеләрен дүрт төркемгә бүләләр/

**Убыр:** Әйе, минем урманымда юкка гына, юлда да акыл кирәк,- дип әйтмиләр икән.

**Ал.бар:** Бик дөрес әйтәләр, юл сүзе кергән мәкаль-әйтемнәрне безнең балалар да беләләр:

- Юлларыгыз имин булсын.
- Юлда булсаң уяу бул.
- Юлда булсаң бул өлгер, юл кагыйдәләрен бел.
- Юлга чыксаң юлдашын үзеңнән яхшы булсын.
- Юл газабы-гүр газабы.

**Убыр:** Светофор юкка гына өйрәтмәгән икән, барысын да белергә кирәк.Тик менә бу юл билгесе турында бернәрсә дә белмим./"Поезд юлы" билгесен күрсәтә/.

/"Гоубой вагон" көенә Светофор һәм кызыл,сары,яшел киемнән балалар керә. Слайдта поезд рәсеме күрсәтелә/

**1 бала:** Олы юлны кисеп уза
Тимер юл шпаллары.
Җилдәй җитез поезд килә,
Шундый күп вагоннары.
Шуның кадәр вагоннарны
Санап кына син өлгер.
Бер,ике,өч,...дүрт,биш,алты...
Кайсыбыз икән өлгер?..
Иң алдан энем кычкырды:

**2 бала:** Ун вагон,биш тәгәрмәч...

**1 бала**: Булы-ы-ы-р!-дигән булдым үзем
Санап өлгерәлмәгәч.

**Убыр:** Светофор да рәхим итеп безгә килеп җитте.

**Светофор:** Убыр, син кая китеп югалдың?

**Убыр**: Мин инде барысын да беләм. Юл кагыйдәләре турында да,мсветофор турында да.

**Светофор**: Барысын да, барысын да, минем төсләрем турында да беләсеңме? Ярый, хәзер без тикшерербез,әйдә икәү минем турында шигырь сөйлибез:
Кабынды кызыл күзе -
Бигрәк таләпчән үзе:

**Убыр:** Юлга чыкма син чабып,

**Светофор:** Тукта, алда юл ябык.
Балкыды сары күзе -
Кыскарак аның сүзе:

**Убыр:** Бераз гына көтәрсез,

**Светофор:** Аннан ары үтәрсез.
Яшел күзе-юмарт ут,
Кабынса юллар ачык.

**Убыр:** Җәяүле, юл аркылы

**Светофор:** Яшел утка гына чык!

Дөрестән дә, сынатмадың Убыр, беләсең икән барысын да.Мин үзем генә түгел дусларым белән килдем.

\Кызыл, сары, яшел киемнән балалар биюе\

**Убыр:** Рәхмәт, дуслар, сезнең белән үзем дә биеп китәрдәй булдым.

**Ал.бар:** Әйдә,Убыр, бергәләп светофор җырын җырлап алабыз.

Р. Фәрхетдинованың "Светофор" җыры.

**Убыр:** Сезнең белән бигрәк күңелле булды. Юл кагыйдәләрен өйрәнеп кенә калмыйча, искиткеч шигырьләр дә тыңладым.

**Ал.бар:** Убыр, ә син бу матур шигырьләрне кем язганын беләсеңме соң?

**Балалар:** Безнең Әлмәттә яшәп иҗат итүче Резеда апа Фәрхетдинова язган.

**Ал.бар:** Резеда Насыйховна бүген бездә кунакта.Әйдәгез, без аны сәламләп бирергә чакырыйк. Рәхим итегез, Резеда Насыйховна, сезгә сүз бирәбез.

/Язучы белән әңгәмә/

**Ал.бар:** Хөрмәтле Резеда Насыйховна бүгенге очрашуга килгәнегез , кызыклы әңгәмәгез өчен сезгә зур рәхмәт. Киләсе очрашуга кадәр, сау булыгыз.